ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы унсигезенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. 2025 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабы.
2. Җиһаншин Азат Илдус улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты составындагы үзгәреш турында.
4. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
5. 2025 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге турында доклад.
6. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2025 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертү хакында хисап.
7. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 156-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 155-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 159-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 162-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм $17^1$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 157-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Нурлат районы Покровский поселогын бетерү турында һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 161-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $6^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 150-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 153-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 154-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 158-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 160-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 152-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 151-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

20. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.

21. «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1115068-8 номерлы федераль закон проекты турында (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү процедурасын камилләштерү максатларында).

22. «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1087937-8 номерлы федераль закон проекты турында (урнашу урыннарында хезмәтләр күрсәтүне хокукый җайга салуны камилләштерү хакында).

23. «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 1102492-8 номерлы федераль закон проекты турында (экскурсоводлар (гидлар) һәм тәрҗемәче гидлар эшчәнлеген һәм туристлык индустриясе өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) хокукый җайга салуны камилләштерү хакында).

24. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 17 һәм 34 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1087178-8 номерлы федераль закон проекты турында (гаиләдә белем алу рәвешендә белем алучы балаларга арадаш аттестацияне һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен үтүнең мәҗбүри булуын билгеләү өлешендә).

25. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1068218-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәтәр уеннар рекламасына карата таләпләрне бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

26. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге $333^{28}$ статьясының 1 пунктындагы 7 пунктчасының үз көчен югалтуын тану турында» 1136782-8 номерлы федераль закон проекты хакында (чит ил паспорты бланкларыннан балалар турында язмаларны планлаштырылган төшереп калдыруга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклый торган паспортка үзгәрешләр керткән өчен дәүләт пошлинасын бетерү өлешендә).

27. Хөкүмәт сәгате: «2025 елда Татарстан Республикасында партнерлык финанславы экспериментын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре. 2026 елга планнар һәм бурычлар».

28. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 537-VII ДС